КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 июль г.Казань № 815

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль милектә булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләрен ясау өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарын билгеләү турында» 2016 ел, 9 июнь, 384 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль милектә булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләрен ясау өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарын билгеләү турында» 2016 ел, 9 июнь, 384 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарын» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органнарын» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше» сүзләре алдындагы «дәүләт хакимияте органнарының» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынучы органна-

рына» сүзләрен «кызыксынучы республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин